ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.07.2024 г.Лениногорск № 199

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 1 июнендәге 146 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 1 июнендәге 146 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 01.01.2024 елдан физик затның вафат булуы яисә аны үлгән дип

игълан итү көненнән соң өч еллык срокның тәмамлануы, Граждан-процессуаль законнарда билгеләнгән тәртиптә, әгәр закон буенча да, васыять буенча да варислар булмаса, йә варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы булмаса яисә барлык варислар мирас алудан читләштерелсә, йә варисларның берсе дә мирас алмаган, йә барлык варислар мирас алудан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса»;

б) 1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «8) 2024 елның 01 гыйнварына 2024 елның 1 гыйнварына кадәр бетерелгән җирле салымнар буенча бурыч булу»; в) 1 пунктның 10, 11 подпунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирасны кабул итмәгән очракта, мирас ачылган көннән алып бер ел эчендә вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның 2024 елның 1 гыйнварына бурычы булу;

11) 2024 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән түләтү турында судка гариза бирү срогы тәмамлангач, физик затларның җирле салымнар буенча 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.»

г) карарның 1 пунктындагы 12 һәм 13 пунктчаларын төшереп калдырырга;

д) карарны түбәндәге эчтәлекле 2 пункт белән тулыландырырга: "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) карарның 1 пунктының 1, 10 бүлекләрендә күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) физик затның вафат булуына бәйле рәвештә салым органнарында исәптән төшерелүе турында белешмәләр;

в) мирас алуга хокук турында таныклык бирү турында белешмәләрнең булмавы хакында салым органы белешмәсе;

2) карарның 1 пунктының 8 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым юкка чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) карарның 1 пунктының 11 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда, - 500 сумнан артмаган суммада бурыч булуы турында салым органы белешмәсе.»;

д) 2, 3, 4, 5 пунктларны тиешенчә 3, 4, 5, 6 пунктлар дип санарга.

4. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми

хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов